**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы **№ 48** **25** февраль **2022** ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының **2012** елның **24** октябереннән **43** номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында **(22.02.2013** № **5,10.06.2015** №**81, 20.08.2018** № **104** карарлар редакциясендә**)**

«Россия Федерациясе Граждан кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» **2021** елның **21** декабрендәге **430**-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә
Балтач авыл җирлеге Советы карар итте:

**1.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының **2012** елның **24** октябереннән **43** номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә **(22.02.2013** № **5, 10.06.2015** № **81, 20.08.2018** № **104** карарлар редакциясендә**)**, **14.2** пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«**14.2.** Хуҗасыз күчемсез әйбер исәпкә куелган көннән соң бер ел үткәч, ә линияле объектны исәпкә куйган көннән соң өч ай узгач орган, җирлекнең башкарма комитеты, бу әйбергә муниципаль милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итә ала.».

**2.** Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: **http://pravo.tatarstan.ru.** һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: **http//aznakayevo.tatarstan.ru**.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов